# КАРАР

**16 ноябрь, 2024 ел** **№ 1**

**Кукмара муниципаль районы Починок-Кучук авыл җирлеге Кенә Баш авылында гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2024 елның 16 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча узган гражданнар җыены этаплары нәтиҗәләре буенча 2024 елның 16 ноябрендә гражданнар җыенының беркетмәсе төзелде:

«Сез 2025 елда Кукмара муниципаль районының Починок Кучук авыл җирлеге Кенәбаш авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 һәм 2 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә срокلы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- тышкы урам яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм аларга бирелгән башка подстанцияләрне һәм мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (урам яктыртуны ремонтлау һәм карап тоту, проект-смета документлары, комплектлау материаллары сатып алу, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү, урам яктыртуны карап тоту буенча башка эш төрләре);

- су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су суырту манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган инженерлык корылмалары төзү һәм ремонтлау (су суырту манарасын, су саклау зонасын, су белән тәэмин итү челтәрен һәм ул тирәдәге территорияләрне карап тоту, ремонтлау, төзү һәм төзекләндерү, проект-смета документлары, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү);

- җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне) төзекләндерү (Кенәбаш авылы чишмәләрен һәм аның тирәсендәге территорияләрне төзекләндерү, төзү һәм карап тоту, проект-смета документлары, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү һәм территорияләрне төзекләндерү буенча башка эш төрләре);

- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (янгынга каршы җиһазлар, савытлар, гидрантлар һәм комплектлау материаллары сатып алу, урнаштыру, карап тоту, шул исәптән проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (урам юл челтәрен карап тоту, җиһазлар, запас частьләр сатып алу, проект-смета документлары, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү),

(урам юлларына вак таш салу, вак таш белән юллардагы чокырларны ремонтлау, проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, вак таш сатып алу, килешү буенча эш өчен түләү, вак таш салу һәм чокырларны ремонтлау буенча башка төр эшләр),

(зиратка илтә торган юлга вак таш салу һәм чокырларны ремонтлау, проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, килешү буенча эш өчен түләү),

(юлны асфальтлау, проект-смета документлары, техник күзәтчелекне һәм экспертизаны гамәлгә ашыру, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү);

- торак пункт территориясен төзекләндерү (территорияне төзү, төзекләндерү, тоту һәм җиһазландыру, проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү, башка эш төрләре),

(массакүләм ял итү урыннарын (парклар, скверлар, спорт мәйданчыклары, мәдәни чаралар уздыру урыннары һәм башка массакүләм ял итү урыннары, хезмәт күрсәтү өчен техника сатып алу) һәм янәшәдәге территорияләрне төзү, тоту, төзекләндерү, җиһазландыру һәм ремонтлау, инвентарь, җиһазлар һәм кече архитектура формаларын сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документлары, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, материал сатып алу, ташу, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү, массакүләм ял итү урыннарын һәм янәшәдәге территорияләрне урнаштыру, тоту, төзекләндерү һәм җиһазландыру буенча башка эш төрләре);

- традицион күмү урыннарын ремонтлау, коймалар төзү, төзекләндерү (Кенәбаш авылы зираты территориясен төзекләндерү һәм карап тоту, инвентарь сатып алу, проект-смета документлары, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү, зират территориясен төзекләндерү һәм карап тоту буенча башка эш төрләре)

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыенының йомгаклау беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлекләренә барлыгы 221 кеше кертелгән, тавыш бирүләрдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны – 128 кеше.

Тавыш бирүләр нәтиҗәләре буенча, гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 119 кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 9 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә күпчелек тавыш белән гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Починок-Кучук авыл җирлегенең Кенә Баш авылында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. 2025 елда Кукмара муниципаль районының Починок-Кучук авыл җирлеге Кенә Баш авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 1000 сум күләмендә үзара салым кертүне һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүне расларга карар кабул иттек:

- тышкы урам яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм аларга бирелгән башка подстанцияләрне һәм мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (урам яктыртуны ремонтлау һәм карап тоту, проект-смета документлары, комплектлау материаллары сатып алу, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү, урам яктыртуны карап тоту буенча башка эш төрләре);

- су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су суырту манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган инженерлык корылмалары төзү һәм ремонтлау (су суырту манарасын, су саклау зонасын, су белән тәэмин итү челтәрен һәм ул тирәдәге территорияләрне карап тоту, ремонтлау, төзү һәм төзекләндерү, проект-смета документлары, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү);

- җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне) төзекләндерү (Кенәбаш авылы чишмәләрен һәм аның тирәсендәге территорияләрне төзекләндерү, төзү һәм карап тоту, проект-смета документлары, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү һәм территорияләрне төзекләндерү буенча башка эш төрләре);

- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (янгынга каршы җиһазлар, савытлар, гидрантлар һәм комплектлау материаллары сатып алу, урнаштыру, карап тоту, шул исәптән проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (урам юл челтәрен карап тоту, җиһазлар, запас частьләр сатып алу, проект-смета документлары, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү),

(урам юлларына вак таш салу, вак таш белән юллардагы чокырларны ремонтлау, проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, вак таш сатып алу, килешү буенча эш өчен түләү, вак таш салу һәм чокырларны ремонтлау буенча башка төр эшләр),

(зиратка илтә торган юлга вак таш салу һәм чокырларны ремонтлау, проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, килешү буенча эш өчен түләү),

(юлны асфальтлау, проект-смета документлары, техник күзәтчелекне һәм экснертизаны гамәлгә ашыру, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү);

- торак пункт территориясен төзекләндерү (территорияне төзү, төзекләндерү, тоту һәм җиһазландыру, проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү, башка эш төрләре),

(массакүләм ял итү урыннарын (парклар, скверлар, спорт мәйданчыклары, мәдәни чаралар уздыру урыннары һәм башка массакүләм ял итү урыннары, хезмәт күрсәтү өчен техника сатып алу) һәм янәшәдәге территорияләрне төзү, тоту, төзекләндерү, җиһазландыру һәм ремонтлау, инвентарь, җиһазлар һәм кече архитектура формаларын сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документлары, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, материал сатып алу, ташу, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү, массакүләм ял итү урыннарын һәм янәшәдәге территорияләрне урнаштыру, тоту, төзекләндерү һәм җиһазландыру буенча башка эш төрләре);

- традицион күмү урыннарын ремонтлау, коймалар төзү, төзекләндерү (Кенәбаш авылы зираты территориясен төзекләндерү һәм карап тоту, инвентарь сатып алу, проект-смета документлары, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү, зират территориясен төзекләндерү һәм карап тоту буенча башка эш төрләре).

Карарны кабул ителгән дип санарга.

3. Гражданнар җыенның нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Починок-Кучук авыл җирлеге
башлыгы урынбасары — Г.И. Петров

ОГРН 1021607752924
ИНН 1623001741